КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 25 декабрь г.Казань № 1035

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләрен раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1044 нче карары белән расланган 2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре Программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләрен раслау турында» 2016 ел, 29 декабрь, 1044 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 ноябрь, 864 нче карары белән расланган үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре Программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне керетргә:

VII бүлектә:

икенче – кырыгынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«медицина оешмасыннан читтә, медицина эвакуациясен дә кертеп, ашыгыч

медицина ярдәме 2017 – 2019 елларга бер яшәүчегә – 0,02 чакыру, ММИ база программасы кысаларында – иминиятләнгән бер затка 0,3 чакыру;

амбулатория шартларында поофилактик яки бүтән максатларда күрсәтелә торган медицина ярдәме (сәламәтлек үзәкләрендә баруны, диспансеризация белән бәйле баруны, урта медицина персоналында баруны, шулай ук авырулар белән бәйле, шул исәптән авыз эче, төкерек бизләре һәм казналык авырулары вакытында бер тапкыр барулар, теш протезлаудан тыш) 2017 – 2019 елларга ММИ база программасы кысаларында – иминиятләнгән бер затка – 2,35 бару, Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер яшәүчегә 0,34 бару, шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 2,07 бару;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 0,28 бару;

медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә 0,33 бару;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә 0,01 бару;

авырулар белән бәйле амбулатория шартларында 2017 – 2019 елларга ММИ база программасы кысаларында медицина ярдәме күрсәтү – иминиятләнгән бер затка 1,98 мөрәҗәгать (бер авыру белән кимендә ике тапкыр бару белән амбулатория шартларында авыруны дәвалауның тәмамланган очраклары), 2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер яшәүчегә 0,07 мөрәҗәгать, шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 1,87 мөрәҗәгать;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 0,11 мөрәҗәгать;

медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 0,06 мөрәҗәгать;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 0,01 мөрәҗәгать;

2017 – 2019 елларга ММИ база программасы кысаларында амбулатория шартларында ашыгыч формада күрсәтелә торган медицина ярдәме – иминиятләнгән бер затка 0,56 мөрәҗәгать, шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 0,5 бару;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 0,06 бару;

2017 – 2019 елларга ММИ база программасы кысаларында көндезге стационар

шартларында күрсәтелә торган медицина ярдәме – иминиятләнгән бер затны дәвалауның 0,06 очрагы, 2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер яшәүчене дәвалауның 0,003 очрагы, шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 0,02 дәвалау очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 0,03 дәвалау очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең өченче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка 0,01 дәвалау очрагы;

медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә 0,001 дәвалау очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә 0,001 дәвалау очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең өченче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә 0,001 дәвалау очрагы;

2017 – 2019 елларга ММИ база программасы кысаларында стационар шартларында күрсәтелә торган махсуслаштырылган медицина ярдәме – иминиятләнгән бер затка госпитализацияләүнең 0,17316 очрагы, шул исәптән 2017 – 2019 елларга ММИ база программасы кысаларында «Медицина тернәкләндерүе» профиле буенча медицина ярдәме күрсәтүче махсуслаштырылган медицина оешмаларында һәм медицина оешмаларының тернәкләндерү бүлекләрендә медицина тернәкләндерүе – иминиятләнгән бер затка 0,047 койка-көн, 2017 – 2019 елларга Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – бер затка госпитализацияләүнең 0,014 очрагы, шул исәптән:

медицина оешмалары өчен ММИ база программасы кысаларында:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка госпитализацияләүнең 0,04396 очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка госпитализацияләүнең 0,07931 очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең өченче дәрәҗәсе – иминиятләнгән бер затка госпитализацияләүнең 0,04989 очрагы;

медицина оешмалары өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән:

медицина ярдәме күрсәтүнең беренче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә госпитализацияләүнең 0,001 очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең икенче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә госпитализацияләүнең 0,005 очрагы;

медицина ярдәме күрсәтүнең өченче дәрәҗәсе – бер яшәүчегә госпитализацияләүнең 0,008 очрагы;

Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбеннән стационар шартларда паллиатив медицина ярдәме (хосписларны һәм сестра

тәрбиясе хастаханәләрен кертеп) – бер яшәүчегә 0,018 койка-көн.

Программа буенча тулаем алганда югары технологияле медицина ярдәме күләме (шул исәптән федераль башкарма хакимият органнары ведомствосындагы медицина оешмалары күрсәтә торган ММИ база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме) 2017 – 2019 елларга бер яшәүчегә исәпләгәндә госпитализацияләүнең 0,006 очрагы.»;

VIII бүлектә:

1 пунктның икенче – тугызынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән ашыгыч медицина ярдәмен чакыру – 2 568,2 сум, ММИ акчасы исәбеннән – 1 850,5 сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән медицина оешмалары (аларның структур бүлекчәләре) амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәткәндә профилактик һәм бүтән максатларда бер бару – 541,1 сум, ММИ акчасы исәбеннән – 392,0 сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән медицина оешмалары (аларның структур бүлекчәләре) амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәткәндә авыру сәбәпле бер бару– 1 480,8 сум, ММИ акчасы исәбеннән – 1 061,7 сум;

ММИ акчасы исәбеннән амбулатория шартларында ашыгыч формада медицина ярдәме күрсәткәндә бер бару – 481,6 сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән көндезге стационар шартларында дәвалауның бер очрагы – 16 996,8 сум, ММИ акчасы исәбеннән – 12 045,6 сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында (аларның структур бүлекчәләрендә) госпитализацияләүнең бер очрагы – 78 433,1 сумя, ММИ акчасы исәбеннән – 24 312,4 сум;

«Медицина тернәкләндерүе» профиле буенча медицина ярдәме күрсәтүче махсуслаштырылган медицина оешмаларында һәм медицина оешмаларының тернәкләндерү бүлекләрендә медицина тернәкләндерүе буенча бер койка-көн ММИ акчасы исәбеннән – 1 757,1 сум;

стационар шартларда паллиатив медицина ярдәме (хосписларны һәм сестра тәрбиясе хастаханәләрен кертеп) күрсәтүче медицина оешмаларында (аларның структур бүлекчәләрендә) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 383,9 сум.»;

5 пунктның алтынчы – җиденче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«медицина оешмалары һәм ашыгыч медицина ярдәме бүлекчәләре табибларына, фельдшерларына һәм медицина туташларына медицина оешмасыннан читтә күрсәткән ашыгыч медицина ярдәме өчен;

табиб-белгечләргә амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәткән өчен.»;

11 пунктның икенче – алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбеннән (бер

яшәүчегә исәпләгәндә) 2017 елда – 3 024,4 сум, 2018 елда – 3 154,2 сум, 2019 елда – 3 264,3 сум;

ММИ база программасын финанслауга ММИ акчасы исәбеннән (иминиятләнгән бер затка исәпләгәндә) 2017 елда – 8 856,9 сум, 2018 елда – 10 325,8 сум, 2019 елда – 10 861,9 сум.

2017 елда Программаның бәясе – 44 981 380,2 мең сум, 2018 елда – 51 003 487,7 мең сум, 2019 елда – 53 443 850,5 мең сум (әлеге Программага 3 нче һәм 4 нче кушымталар), шул исәптән:

2017 елда база программасын тормышка ашыруга ММИ акчасы исәбеннән – 33 280 980,8 мең сум, 2018 елда – 38 800 714,5 мең сум, 2019 елда – 40 815 311,9 мең сум;

2017 елда Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбеннән – 11 700 399,4 мең сум, 2018 елда – 12 202 773,2 мең сум, 2019 елда – 12 628 538,6 мең сум.»;

1 нче кушымтада 124 пунктны төшереп калдырырга;

3 нче һәм 4 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгәннәр).

2. Бу карарның көче 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин